ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 апрель 2021 ел № 2466

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6, 39.17, 39.20 статьялары, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4348 номерлы;

2) «Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 30 июнендәге 3382 номерлы;

3) «Башкарма комитетның «Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4348 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 16 августындагы 4800 номерлы;

4) «Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 октябрендәге 6172 номерлы;

5) «Башкарма комитетның «Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4348 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 29 ноябрендәге 7121 номерлы;

6) «Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 8 маендагы 2395 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2021 елның 9 апрелендәге
2466 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә
арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – регламент) муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

Регламентның гамәлдә булуы муниципаль милектәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына кагыла.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясының 2 пунктында күрсәтелгән физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче) (2 нче кушымта).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Башкарма комитет).

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе (алга таба – ҖММИ).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

ҖММИнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 233 кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр

төшке аш: 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр

ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

ҖММИнең белешмә телефоны: 30-55-54.

Башкарма комитет бинасына керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: http://nabchelny.ru.

ҖММИнең электрон почта адресы: uzioip@yandex.ru.

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат түбәндәге юл белән алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://gosuslugi.ru);

5) Башкарма комитетта (ҖММИ):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта аша электрон формада.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Граждан кодексы (алга таба – РФ Граждан кодексы);

2) Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы);

3) «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 137-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2001, № 44, 4148 ст.);

4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.10.2003, № 40, ст. 3822);

5) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179);

6) «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-218-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.07.2015, №29 (1 өлеш), ст.4344);

7) «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.11.1995, № 48, ст. 4563);

8) «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 11.04.2011, № 15, ст. 2036);

9) Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең «Гариза бирүченең сату үткәрмичә җир участогын алу хокукын раслый торган документлар исемлеген раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге П/0321 номерлы приказы (алга таба-П/0321 номерлы Приказ);

10) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 елның 9 февралендәге 74 номерлы карары (алга таба – 74 номерлы карар);
11) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав) (Челнинские известия, № 235-237, 10.12.2005; № 249-250, 30.12.2005);

12) Башкарма комитетның 2021 елның 3 мартындагы 1441 номерлы карары белән расланган Муниципаль хезмәтләр исемлеге (алга таба – Муниципаль хезмәтләр исемлеге);

13) Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

14) Башкарма комитетның 2017 елның 28 декабрендәге 1210-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезләмә (алга таба – ҖММИ турында нигезләмә);

15) Башкарма комитетның 2020 елның 25 февралендәге 101-р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр файдаланыла:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба-гариза) – муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос (1 нче кушымта);

2) техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә

китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

3) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны (алга таба – К ФҮнең ерактагы эш урыны) – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Яр Чаллы шәһәрендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең (алга таба – КФҮ) территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен хокукый нигезләр |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү | РФ Җир кодексының<br>39.6, 39.17 статьялары;<br>Муниципаль хезмәтләр исемлеге |
| 2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме | Башкарма комитет исеменнән ҖММИ | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы;<br>РФ Җир кодексының 39.2 статьясы;<br>шәһәр Уставының 41 статьясы;<br>ҖММИ турында нигезләмә |
| 2.3. Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган структур бүлекчәләре исемлеге | 1) ҖММИ;<br>2) Башкарма комитетның хокук идарәсе (алга таба – Хокук идарәсе);<br>3) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) | Эш регламентының 3 бүлеге |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Җир участогына аренда шартнамәсе яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ Граждан кодексының 606 статьясы<br>РФ Җир кодексының 39.17 статьясы |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Гаризаны теркәгән вакыттан башлап 30 календарь көннән артык түгел | РФ Җир кодексының<br>39.2 статьясындагы 5 пункты |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле | 1) Гариза;<br>2) гариза бирүченең яисә гариза бирүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ;<br>3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән аның вәкиле эш иткән очракта);<br>4) мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очракта, | РФ Граждан кодексының<br>49, 182 статьялары;<br>РФ Җир кодексының 39.17 статьясы;<br>П/0321 номерлы Приказ |

| | | |
|---|---|---|
| документларның тулы исемлеге | чит дәүләт законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның расланган рус теленә тәрҗемәсе;<br>5) юридик затның гамәлгә кую документының күчермәсе.<br>Муниципаль хезмәт алучыларның категориясенә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелә торган өстәмә документлар исемлеге 3 нче кушымтада китерелгән. | |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм, алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш булу сәбәпле, гариза бирүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт алучыларның категориясенә бәйле өстәмә документлар исемлеге 3 нче кушымтада китерелгән | П/0321 номерлы Приказ;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.1. статьясы;<br>218-ФЗ номерлы Федераль законның 62 статьясы |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документлар тиешле булмаган зат тарафыннан бирелү;<br>2) тапшырылган документлар әлеге регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;<br>3) документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлатмый торган җитди кимчелекләр булу;<br>4) документларны тиешле булмаган органга тапшыру | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр: | РФ Җир кодексының 39.6 статьясындагы 4, 5 пунктлары, 39.16 статьясы, 46 статьясының 5 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | 1) җир участогы бирү турындагы гариза белән җир законнары нигезендә җир участогын сатулар үткәрмичә алу хокукына ия булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>2) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы даими (сроксыз) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мираска ия булу яки аренда хокукында бирелгән, җир участогы бирү турында гариза белән әлеге хокукларга ия булучы мөрәҗәгать иткән яисә җир участогы бирү турында гариза РФ Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә бирелгән очраклардан тыш;<br>3) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләренә бирелгән җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән, мондый гариза белән әлеге ширкәт әгъзасы (әгәр мондый җир участогы җимеш бакчасы яки яшелчә бакчасы булса) яисә гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан җир участоклары милекчеләре мөрәҗәгать итү очракларыннан тыш;<br>4) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында гражданнарга яисә юридик затларга караган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, аларны урнаштыру сервитут, гавами сервитут нигезендә рөхсәт ителә торган корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яки РФ Җир кодексының 39.36 статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан яисә җир участогы бирү турында гариза белән әлеге бина, корылма, алардагы бина, әлеге тәмамланмаган төзелеш объектының милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, шулай ук анда урнашкан биналар, корылмалар, тәмамланмаган төзелеш объектына карата рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турында карар кабул ителгән яисә | |

| | | |
|---|---|---|
| | билгеләнгән таләпләр нигезендә рөхсәтсез корылманы сүтү яки күрсәтелгән карарлар белән билгеләнгән срокларда аны тәртипкә китерү буенча Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55.32 статьясындагы 11 өлештә билгеләнгән йөкләмәләр үтәлмәгән җир участогын бирү турында гариза бирелгән очраклардан тыш;<br>5) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашкан, җир участогында аларны урнаштыру сервитут, гавами сервитут нигезендә рөхсәт ителгән корылмалар (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмалар) яисә РФ Җир кодексының 39.36 статьясы нигезендә урнашкан объектлар урнашкан яисә җир участогы бирү турында гариза белән әлеге биналар, корылмалар, алардагы бүлмәләр, әлеге тәмамланмаган төзелеш объектының хуҗасы мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>6) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы әйләнештән алынган яисә әйләнештә чикләнгән булып тора һәм аны бирү җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокук буенча рөхсәт ителми;<br>7) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган җир булып тора, әгәр мөрәҗәгать итүче җир участогын милеккә, даими (сроксыз) файдалануга яисә җир участогын арендага бирү турындагы гариза белән, җир участогын резервлау максатларында җир участогы бирү турындагы карарның гамәлдә булу срогыннан артык вакытка түләүсез файдалануга бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, җир участогын резервлау максатларында бирү очрагыннан тыш;<br>8) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата башка зат белән төзелә торган территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | территория чикләрендә урнашкан, җир участогы бирү турында гариза белән шул җир участогында урнашкан бина, корылмалар, алардагы бүлмәләрнең, тәмамланмаган төзелеш объектының милекчесе яки җир участогының хуҗасы мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>9) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогы чикләрендә урнашкан яки җир участогы башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогыннән ясалган, мондый җир участогы федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир участогын бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>10) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогыннән төзелгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документ нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән, җир участогын арендага бирү турындагы гариза белән әлеге затның әлеге объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тотучы территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>11) җир участогын бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогы, аны үткәрү турында белдерү РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 19 пункты нигезендә урнаштырылган аукцион предметы булып тора;<br>12) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата, мондый җир участогы РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктның 4 пунктчасы | |

| | | |
|---|---|---|
| | нигезендә ясалган һәм вәкаләтле орган тарафыннан, РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 8 пунктында каралган нигезләр буенча, әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән булса, аны сату буенча РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктының 6 пунктчасында каралган аукцион яки арендага алуга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү турында гариза кергән;<br>13) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата РФ Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге өчен җир участогы бирү турында белдерү басылып чыккан һәм урнаштырылган;<br>14) җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану мондый җир участогыннан җир участогы бирү турында гаризада күрсәтелгән файдалану максатларына туры килми, линия объектын территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә урнаштыру очракларыннан тыш;<br>15) соралган җир участогы тулысынча территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чикләрендә урнашкан, анда җир участокларыннан файдалануның билгеләнгән чикләүләре буенча әлеге җир участогыннан җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогыннан файдалану максатлары нигезендә файдаланырга рөхсәт ителми;<br>16) соралган җир участогы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча кулланылмый торган җир участоклары исемлегенә кертелмәгән, әгәр җир участогы бирү турында гариза РФ Җир Кодексының 39.10 | |

| | | |
|---|---|---|
| | статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә бирелгән булса;<br><br>17) коммерцияле булмаган бакчачылык яки бакчачылык ширкәтенә җир участогы бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы РФ Җир кодексының 39.10 статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән чик күләменнән артып китә;<br>18) җир участогы бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогы территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру буенча документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир участогы бирү турында гариза белән әлеге объектлар төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>19) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә бина, корылмалар урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир участогы бирү турында гариза белән әлеге биналар, корылмаларны төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>20) билдерелгән хокуклар буенча җир участогы бирү рөхсәт ителми;<br>21) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогына карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән;<br>22) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы җирләрнең билгеле бер категориясенә кертелмәгән;<br>23) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата аны бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән һәм аның гамәлдә булу срогы чыкмаган | |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм җир участогы бирү турындагы гариза белән бу карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать иткән;<br>24) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган һәм гаризада күрсәтелгән җир участогын бирү максаты мондый җир участогын тартып алу максатларына туры килми, мондый җир участогында урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тануга бәйле рәвештә дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир участокларыннан тыш;<br>25) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогының чикләренә 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төгәллек кертелергә тиеш;<br>26) аны бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы алар нигезендә мондый җир участогы төзелгән җир участогының урнашу схемасы, территорияне межалау проекты яисә урман участокларының проект документларында күрсәтелгән мәйданыннан ун проценттан артып китә;<br>27) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешендә каралган дәүләт милке исемлегенә яисә муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән җир участогы бирү турындагы гариза белән кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты булмаган зат яисә күрсәтелгән Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ярдәм күрсәтелә алмый торган зат мөрәҗәгать иткән. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм федераль законнарда, алар нигезендә | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| кабул ителә торган башка норматив хокукый актларда каралган очракларда аны алу ысуллары | | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәттән файдалануга гариза бирү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу –15 минуттан артык түгел | |
| 2.12. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтеп тору залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрослар тутыру урыннарына, һәрбер муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге һәм аларны тутыру үрнәкләре язылган мәгълүмат стендларына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә таләпләр | 1) муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>3) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге; | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 12 пункты;<br>181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | - күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе җитди бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- аларның яшәеш мөмкинлекләре чикле булуны исәпкә алып, инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен һәм хезмәтләрдән файдалануын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләр бары тик яңа файдалануга тапшырылган яисә реконструкция, модернизация үткән объектлар һәм чаралар буенча гына куела. | |
| 2.14. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) Башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>2) кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза | |

| | | |
|---|---|---|
| | бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>3) мәгълүмат стендларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында яисә Татарстан Республикасы Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>4) инвалидларга башка затлар белән бертигез хезмәт күрсәтүгә комачаулый торган барьерларны узарга ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>1) документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>3) муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәвенә) шикаятьләр;<br>4) муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр. | |
| 2.15. Башка, шул исәптән муниципаль хезмәтне КФҮдә күрсәтү үзенчәлекләрен һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен искә алучы таләпләр | 1) Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи зат белән гариза бирүченең бер тапкыр хезмәттәшлек итүе күздә тотыла.<br>Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра.<br>2) Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон формада бирү законда каралган булса, ул очракта гариза | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлешенең 1 пункты; |

| | | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша бирелә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.<br>Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүгә күчү муниципаль хокукый актлар белән расланган план-график нигезендә гамәлгә ашырылачак | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны КФҮдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросла формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү һәм гариза бирүчегә бирү;

5) муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү

3.2.1. Гариза бирүче консультация алу өчен ҖММИгә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

ҖММИ белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның (аларның күчермәләренең) составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр.

3.2.2. Муниципаль хезмәттән электрон формада файдалану тәртибе турында консультацияне ТР Муниципаль берәмлекләре порталының Интернет-кабул итү (https://msu.tatarstan.ru) яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша алырга мөмкин.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән зат шәхсән яки КФҮ, КФҮнең еравктагы эш урыны аша эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә гариза бирә һәм әлеге регламентның 2.6 пункты күрсәтелгән документларны тапшыра. КФҮнең ерактагы эш урыннары исемлеге регламентка 5 нче кушымтада бирелгән.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) гариза бирүченең һәм гариза бирүче вәкиленең шәхесен ачыклауны;

2) гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы белән эш иткән очракта);

3) регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерүне;

4) тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерүне (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозып язулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасыннан файдаланып гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;

2) керә торган документларның теркәү карточкасын төзүне;

3) гариза бирүчегә, документларны кабул итү датасын куеп, гаризаның күчермәсен (булганда) тапшыруны;

4) гаризаны һәм теркәлгән документларны бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече регламентның 2.8. пункты нигезендә гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрнең эчтәлеген аңлатып, гаризаны һәм документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

1) гаризаны һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

2) гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган гариза һәм документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны карап тикшерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.4. ҖММИ башлыгы гаризаны, документларны карап тикшерә һәм аларны карап тикшерү өчен ҖММИнең җир ресурслары белән идарә итү бүлеге башлыгына (алга таба – ҖММИ бүлеге башлыгы) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.5. ҖММИ бүлеге башлыгы гаризаны, документларны карап тикшерә һәм аларны карап тикшерү өчен ҖММИнең җиргә кагылышлы аренда мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге белгеченә (алга таба – ҖММИ бүлеге белгече) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.1. ҖММИ бүлеге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында запрослар җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формада җибәрелгән ведомствоара запрослар.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, соралган мәгълүматларны бирә яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүматлар булмау турында белдерү кәгазе җибәрә (алга таба – мәгълүматлар булмау турында белдерү кәгазе).

Җавап әзерләү һәм җибәрү сроклары федераль законнар белән билгеләнә.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән мәгълүматлар яисә мәгълүматлар булмау турында белдерү кәгазе.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Җир участогының кадастр бәясе билгеләнмәгән яисә 0 гә яки 1 сумга тигез күләмдә күрсәтелгән очракта, ҖММИ бүлеге белгече җир участогының базар бәясен билгеләү буенча бәяләүгә заказ бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура муниципаль хезмәт күрсәтү срогына

керми.

Процедураның нәтиҗәсе: җир участогының базар бәясен билгеләү буенча хисап.

3.5.2. ҖММИ бүлеге белгече алынган мәгълүматлар нигезендә:

1) регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр буенча җир участогын арендалау шартнамәсе проектын (алга таба – шартнамә проекты) яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын (алга таба – баш тарту турында хат) әзерли;

2) шартнамә проектын яисә баш тарту турында хатны ҖММИ бүлеге башлыгына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара запросларга җавап кергән вакыттан башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ҖММИ бүлеге башлыгына килештерү өчен җибәрелгән шартнамә проекты яисә баш тарту турында хат.

3.5.3. ҖММИ бүлеге башлыгы шартнамә проектын карап тикшерә, килештерә, килештерү өчен аны ҖММИ башлыгына җибәрә яисә баш тарту турында хатны карап тикшерә, килештерә һәм аны имзалау өчен ҖММИ башлыгы урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура шартнамә проектын яисә шартнамәдән баш тарту турында хат алган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрелгән шартнамә проекты яки имзалау өчен ҖММИ башлыгына җибәрелгән хат.

3.5.4. ҖММИ башлыгы шартнамә проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрә яисә баш тарту турында хатны карап тикшерә, имзалый һәм ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура шартнамә проектын яки килештерүдән баш тарту турында хатны алган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрелгән шартнамә проекты яки имзаланган һәм ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән баш тарту турында хат.

3.5.5. Хокук идарәсе шартнамә проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә. Тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, хокук идарәсе шартнамә проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр әзерли һәм әлеге кимчелекләрне төзәтү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап дүрт эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән шартнамә проекты яки шартнамә проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр.

3.5.6. Хокук идарәсе шартнамә проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр җибәргән очракта, ҖММИ бүлеге белгече кимчелекләрне төзәтә һәм шартнамә проектын килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура күрсәтмәләр кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән, килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрелгән шартнамә проекты.

3.5.7. Хокук идарәсе төзәтелгән шартнамә проектын карап тикшерә, аны килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хокук идарәсе тарафыннан килештерелгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән шартнамә проекты.

3.5.8. Башкарма комитет Җитәкчесе шартнамә проектын имзалый һәм аны теркәү һәм гариза бирүчегә тапшыру өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамлаган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган, ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән шартнамә проекты.

3.5.9. ҖММИ бүлеге белгече:

1) шартнамә проектын терки;

2) гариза бирүчегә (аның вәкиленә), гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә;

3) гариза бирүчегә (аның вәкиленә) шартнамә проектының өч нөсхәсен бирә яисә почта аша җибәрә.

Әлеге пунктның 1, 2 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктның 3 пунктчасында билгеләнә торган процедура әлеге пунктның 2 пунктчасында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

3.5.10. Гариза бирүче шартнамә проекты алынган көннән башлап 30 календарь көн эчендә шартнамә проектын өч нөсхәдә имзалый һәм ҖММИ бүлеге белгеченә тапшыра.

Әлеге процедураның срогы муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүче тарафыннан имзаланган шартнамә.

3.5.11. ҖММИ бүлеге белгече шартнамәне теркәп, аренда хокукын дәүләт теркәвенә алу турында гаризаны хокукларны теркәү органына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында аренда хокукын теркәү.

3.6. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү.

3.6.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә, КФҮнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮдән документлар кергәндә, процедуралар әлеге регламентның 3.3 – 3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта техник хата табылган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә яисә КФҮгә, КФҮнең ерактагы эш урынына түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (4 нче кушымта);

муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүченең (вәкаләтле вәкиленең) шәхсән үзе тарафыннан, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтаны кулланып), яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы яки КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша бирелә.

3.7.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны теркәлгән документлары белән бергә кабул итә, гаризаны терки һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм аңа теркәлгән документлар.

3.7.3. Техник хатаны төзәтү турында гариза кергәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында регламентның 3.3.3 - 3.3.5 һәм 3.5 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

ҖММИ белгече төзәтелгән документны шәхсән гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә, төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып, техник хата булган документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки техник хаталы документның төп нөсхәсен АШТһТҮИгә тапшырганда документны алу мөмкинлеге турындагы хатны гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура җибәрелгән техник хата ачыкланганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынучы заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Регламент үтәлешенең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә тикшерүләр үткәрүне, Башкарма комитет вазыйфаи затларының карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш кәгазьләрен алып баруны билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүен контроль тикшерүләрне билгеләнгән тәртиптә үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәрү вакытында муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә эш итүләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәләре турында мәгълүматлар бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында каралмавы өчен җаваплы.

ҖММИ башлыгы әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ процедураларның үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) – Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләре буенча – КФҮгә яисә гавами-хокукый берәмлекнең КФҮне гамәлгә куючы тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, шулай ук КФҮнең һәм КФҮ хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле

документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, Интернет челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр рәсми сайтыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтүче органның (Башкарма комитет), Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре бирелергә мөмкин.

5.5. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган

уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) гариза бирүчеләр Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесенә

________________________________________________
________________________________________________
________________________________________________
________________________________________________
(физик затлар өчен: Ф.И.А.и., теркәлү урыны һәм гариза бирүченең шәхесен раслаучы документларның реквизитлары, ИНН;

________________________________________________
________________________________________________
________________________________________________
юридик затлар өчен: исеме һәм урнашу урыны, ОГРН, ИНН, гариза бирүче булып чит ил юридик заты торган очрактан тыш)

________________________________________________
________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, телефон номеры)

## Җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү турында гариза

Сездән ____________________________________________________________ нигезендә,
(РФ Җир кодексының 39.6 статьясының 2 пунктында каралган нигез күрсәтелә)

______________________________________________________________________________
Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре адресы буенча урнашкан, _____________________________________ җирләр категориясендәге, рөхсәт ителгән файдалану төре __________________________________________, мәйданы ____________ кв.м, кадастр номеры ___________________________ булган җир участогын
__________________________________________________________________________ өчен
(җир участогыннан файдалану максаты күрсәтелә)

сатулар үткәрмичә арендага бирүегезне сорыйм.

Өстәмә мәгълүматлар (түбәндә күрсәтелгән шартлар булганда тутырыла):

______________________________________________________________________________
дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын алу турында карар реквизитлары, әгәр җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир участогына алмашка бирелсә;

______________________________________________________________________________
территориаль планлаштыру документын һәм (яки) территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар реквизитлары, әгәр җир участогы әлеге документта һәм (яки) әлеге проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелсә;

______________________________________________________________________________
җир участогы бирүне алдан килештерү турында карар реквизитлары, әгәр соралган җир участогы әлеге карар нигезендә барлыкка килсә яки аның чикләре аныкланса.

Гаризага түбәндәге документлар (күчермәләр) теркәлә:

Физик затлар:

1) гариза бирүченең яисә гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклаучы документ;

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

Юридик затлар:

1) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

2) гариза бирүче булып чит ил юридик заты торса, чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның расланган рус теленә тәрҗемәсе.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: __________________.

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | ____________________ | (______________________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.и.) |

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Россия Федерациясе Җир кодексының
39.6 статьясыннан өземтә

2. Түбәндәгеләр бирелгән очракта, дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын арендалау шартнамәсе сатулар үткәрмичә төзелә:

1) Россия Федерациясе Президенты указы яки боерыгы нигезендә юридик затларга җир участогы;

2) әлеге объектларның, инвестиция проектларының Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән критерийларга туры килү шарты белән, социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен, Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыгы нигезендә юридик затларга җир участогы;

3) әлеге объектларның, инвестиция проектларының Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән критерийларга туры килү шарты белән, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен, Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты боерыгы нигезендә юридик затларга җир участогы;

3.1) Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты боерыгы нигезендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) өч һәм аннан күбрәк блоктан торган блоклы төзелеш торак йортларын төзү (булдыру) өчен, төзелеше тәмамланмаган төзелеш объектлары төзелешен тәмамлау һәм төзүченең «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә зыян күргән гражданнар реестрына кертелгән, күпфатирлы йортларны төзү өчен акчалары җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар алдында йөкләмәләрен үтәү буенча, әлеге Федераль закон нигезендә алар турында мәгълүматлар проблемалы объектларның бердәм реестрына кертелгән күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзелешен тәмамлау буенча йөкләмәне үз өстенә алган юридик затларга җир участогы;

4) Россия Федерациясенең халыкара йөкләмәләрен үтәү өчен җир участогы, шулай ук электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су бүлү, элемтә, нефть үткәргечләр белән тәэмин итү өчен билгеләнгән объектларны, федераль, региональ яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен юридик затларга җир участогы;

5) әгәр әлеге пунктның 8 пунктчасында, РФ Җир кодексының 46 статьясының 5 *пунктында* башкача каралмаган булса, мондый җир участогын арендалау шартнамәсе төзелгән затка дәүләт яисә муниципаль милектәге, шул исәптән территорияне комплекслы үстерү өчен бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участогы;

6) үз көчен югалткан – 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон;

7) мондый ширкәт әгъзаларына коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән бакчачылык яки яшелчәчелек җир участогы, гомуми файдаланудагы җир участокларыннан тыш;

8) арендатор ягында күп санлы затлар белән шундый территория чикләрендәге бакчачылык яки яшелчәчелек җир урчастоклары хокукына ия булган гражданнарга,

гражданнар тарафыннан шәхси ихтыяҗлар өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан гомуми билгеләнештәге җир участогы булып исәпләнгән һәм әйләнештә чикләнгән җир участогы (күрсәтелгән җир участогын шундый гражданнарга бирү зарурлыгы шундый территория чикләрендәге гомуми файдаланудагы мөлкәт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышы карарында каралган очракта);

8.1) үз көчен югалткан – 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон;

9) биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең милекчеләренә һәм (яки) хуҗалык алып бару хокукында яки РФ Җир кодексының 39.20 статьясы нигезендә каралган очракларда, оператив идарә итү хокукында әлеге күчемсез милек объектлары бирелгән затларга биналар, корылмалар урнашкан җир участогы;

10) бер тапкыр, әлеге статьяның 5 пунктында каралган очракларда, аларның төзелешен тәмамлау өчен төзелеше тәмамланмаган объектларның милекчеләренә төзелеше тәмамланмаган объектлар урнашкан җир участогы;

11) әлеге җирдән файдаланучыларга юридик затларның даими (сроксыз) файдаланудагы җир участогы, РФ Җир кодексының 39.9 статьясының 2 пунктында күрсәтелгән юридик затлардан тыш;

12) крестьян (фермер) хуҗалыгына яки «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда авыл хуҗалыгы оешмасына җир участогы;

13) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән затка яисә Россия Федерациясе яки Россия Федерациясе субъекты тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны тормышка ашыруны тәэмин итүче юридик затка территория чикләрендә барлыкка килгән җир участогы;

13.1) - 13.3) үз көчен югалткан – 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон;

14) федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә җир участокларын беренче чиратта яки чираттан тыш сатып алу хокукына ия гражданнарга җир участогы;

15) РФ Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә шәхси торак төзү, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык алып бару өчен гражданнарга, крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына җир участогы;

16) гражданга яки юридик затка арендалау хокукында бирелгән һәм дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алына торган җир участогына алмашка җир участогы;

17) авыл хуҗалыгы производствосын гамәлгә ашыру, традицион яшәү рәвешен саклау һәм үстерү һәм Россия Федерациясе субъектларының законнары нигезендә билгеләнгән территориядә казак җәмгыятьләренең хуҗалык итүе өчен дини оешмаларга, Россия Федерациясе дәүләт казак җәмгыятьләре реестрына кертелгән казак җәмгыятьләренә (алга таба – казак җәмгыятьләре) җир участогын;

18) әлеге Кодекс нигезендә дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә алу хокукына ия затка җир участогы, шул исәптән бушлай, әгәр мондый җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган яки әйләнештә чикләнгән булса;

19) печән чабу, авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү, бакчачылык алып бару өчен гражданга яки торак пункт чикләреннән читтә урнашкан җир участогын шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен гражданга җир участогы;

20) җир асты байлыкларыннан файдаланучыга җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр башкару өчен кирәкле җир участогы;

21) федераль бюджет, Россия Федерациясе субъекты бюджеты, җирле бюджет акчалары хисабына махсус икътисадый зона чикләрендә һәм аның янәшәсендәге территориядә күчемсез милек объектларын финанслауның бюджеттан тыш чыганакларын булдыру буенча һәм әлеге һәм элек төзелгән күчемсез милек объектлары белән идарә итү буенча функцияләрне үтәү өчен, аны махсус икътисадый зоналар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җәлеп иткән очракта, махсус икътисадый зона резидентына яки идарәче компаниягә махсус икътисадый зона чикләрендә яки аның янәшәсендәге территориядә урнашкан җир участогы;

22) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләнгән федераль башкарма хакимият органы белән махсус икътисадый зона инфраструктурасын үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешү төзегән затка, әлеге зона инфраструктурасы объектларын төзү өчен, махсус икътисадый зона чикләрендә яки аның янәшәсендәге территориядә урнашкан җир участогы. Махсус икътисадый зона инфраструктурасын үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүнең якынча формасы Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана;

23) күрсәтелгән килешүләрне төзегән затка концессион килешүдә, дәүләт-шәхси партнерлык турында килешүдә, муниципаль-шәхси партнерлык турында килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы;

23.1) коммерцияле файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү өчен яки социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү өчен, коммерцияле файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында килешү яки социаль файдаланудагы наемга алынган йортны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияне үзләштерү турында шартнамә төзегән затка һәм, Россия Федерациясе субъекты законында каралган очракларда, социаль файдаланудагы наемга алынган йортларны төзү һәм эксплуатацияләү максатларында территорияләрне үзләштерү өчен, Россия Федерациясе субъекты яки муниципаль берәмлек тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага җир участогы;

23.2) махсус инвестиция контракты төзегән затка махсус инвестиция контрактында каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы;

24) аучылык хуҗалыгы килешүе төзегән затка аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир участогы;

25) әгәр бу объектларны урнаштыру территориаль планлаштыру документларында федераль, региональ яки җирле әһәмияткә ия объектлар буларак каралган булса, сусаклагычларны һәм (яки) гидротехник корылмаларны урнаштыру өчен җир участогы;

26) автомобиль юлы өчен бүлеп бирелгән полосалар һәм юл буе полосалары чикләрендә «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир участогы;

27) гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты инфраструктурасы объектларын урнаштыру буенча «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир участогы;

28) күрсәтелгән зона чикләрендә инвестиция декларациясе нигезендә инвестиция проектын тормышка ашыру өчен территориаль үсеш зонасы резидентлары реестрына кертелгән территориаль үсеш зонасы резидентына җир участогы;

29) аларны файдалануга бирү турындагы карар, балыкчылык участогыннан файдалану шартнамәсе яки биологик су ресурсларыннан файдалану шартнамәсе

нигезендә, күрсәтелгән карар яки килешүләрдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен, биологик су ресурсларын табу (чыгару) хокукына ия булган затка җир участогы;

29.1) күрсәтелгән максатлар өчен, дәүләт яки муниципаль милектәге балык үрчетү участогыннан файдалану шартнамәсе (алга таба – балык үрчетү участогыннан файдалану шартнамәсе) нигезендә товар аквакультурасын (товар балыгы үрчетүне) гамәлгә ашыручы затка җир участогы;

30) аларны кору турында һәм урнаштыру урыны турында карарлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән атом-төш җайланмаларын, радиация чыганакларын, атом-төш материалларын һәм радиоактив матдәләрне саклау пунктларын, радиоактив калдыкларны саклагычларны, саклау пунктларын һәм радиоактив калдыкларны күмү пунктларын урнаштыру өчен юридик затка җир участогы;

31) шундый җир участогын арендалау буенча яңа шартнамә төзү турындагы гариза әлеге арендатор тарафыннан шундый җир участогын арендалау буенча элек төзелгән шартнамәнең гамәлдәге срогы чыккан көнгә кадәр бирелү шарты белән, вәкаләтле органда дәүләт җир күзәтчелеге кысаларында ачыкланган һәм мондый җир участогыннан файдаланганда Россия Федерациясе законнарын бозу турындагы мәгълүмат булмауга мөнәсәбәтле арендаторга авыл хуҗалыгы производствосын алып бару өчен билгеләнгән җир участогы;

32) әлеге статьяның 3 һәм 4 пунктлары нигезендә арендатор шундый җир участогын арендалау буенча яңа шартнамә төзү хокукына ия булган очракта, арендаторга (әлеге пунктның 31 пунктчасында күрсәтелгән җир участокларының арендаторларыннан тыш) җир участогы;

33) үз көчен югалткан – 2020 елның 15 октябрендәге 318-ФЗ номерлы Федераль закон;

34) «Дәүләт яки муниципаль милектәге һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы составына керүче Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан җир участокларын гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә гражданга җир участогы;

35) «Торак төзелешен үстерүгә ярдәм күрсәтү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җир участогы;

36) Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе башкаласы статусы турында» 1993 елның 15 апрелендәге 4802-1 номерлы Законы нигезендә Россия Федерациясе субъектында – федераль әһәмияткә ия Мәскәү шәһәрендә торак фондын реновацияләү турындагы карарны тормышка ашыру максатларында, «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шундый җир участогында өлешләп төзүдә катнашу шартнамәләре буенча гражданнарның һәм юридик затларның акчаларын җәлеп итеп, күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү планлаштырылган очракта, Россия Федерациясе субъекты – федераль әһәмияткә ия Мәскәү шәһәре тарафыннан төзелгән торак төзелешен реновацияләү буенча Мәскәү фондына Россия Федерациясе субъекты – федераль әһәмияткә ия Мәскәү шәһәре милкендәге яки дәүләт милке чикләнмәгән җир участогы;

37) «Инновацион фәнни-технологик үзәкләр турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә төзелгән фондка инновацион фәнни-технологик үзәк территориясе чикләренә кертелгән җир участогы;

38) «Кырым Республикасын һәм федераль әһәмияткә ия Севастополь шәһәрен үстерү һәм Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияткә ия Севастополь шәһәре территорияләрендә иректе икътисадый зона турында» 2014 елның 29 ноябрендәге

377-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән ирекле икътисадый зонадагы эшчәнлек шартлары турында шартнамәне тормышка ашыру өчен Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияткә ия Севастополь шәһәре территорияләрендәге ирекле икътисадый зонада катнашучыга җир участогы;

39) «Россия Федерациясе Арктика зонасында эшмәкәрлек эшчәнлегенә дәүләт ярдәме турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Арктика зонасы резиденты статусы алган зат тарафыннан Россия Федерациясе Арктика зонасында инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җир участогы;

40) «Төзелеш өлкәсендә бердәм заказчы» гавами-хокукый компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә, агымдагы елга һәм план чорына «Төзелеш өлкәсендә бердәм заказчы» гавами-хокукый компаниясенең эшчәнлек программасына кертелгән инженерлык тикшеренүләрен, архитектура-төзелеш проектларын, капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне, сүтүне тәэмин итү өчен җир участогы.

3. Дәүләт яки муниципаль милектәге җир участокларының арендаторлары булып торган гражданнар һәм юридик затлар түбәндәге очракларда сатулар үткәрмичә, мондый җир участокларын арендалау буенча яңа шартнамә төзергә хокуклы:

1) җир участогы гражданга яки юридик затка сатулар үткәрмичә арендага бирелгән (РФ Җир кодексының 39.12 статьясының 13, 14 һәм 20 пунктларында каралган очраклардан тыш);

2) җир участогы гражданга бакчачылык алып бару өчен аукционда бирелгән.

4. Җир участогының арендаторлары булып торган граждан яки юридик зат, түбәндәге шартлар җыелмасы булганда, әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән мондый җир участогын арендалау буенча яңа шартнамә төзү хокукына ия:

1) әлеге граждан яки әлеге юридик зат тарафыннан шундый җир участогын арендалау буенча яңа шартнамә төзү турындагы гариза җир участогын арендалау буенча элек төзелгән шартнамәнең гамәлдәге срогы чыккан көнгә кадәр бирелү;

2) РФ Җир кодексында, башка федераль законнарда каралган очракларда, шундый җир участогын сатып алуның аерым хокукына башка зат ия булмау;

3) РФ Җир кодексының 46 статьясының 1 һәм 2 пунктларында каралган нигезләр буенча, шундый җир участогын аредалау буенча элек төзелгән шартнамә әлеге граждан яки юридик зат тарафыннан туктатылмау;

4) шундый җир участогын арендалау буенча яңа шартнамә төзү моментына, сатулар үткәрмичә аренда шартнамәсе төзелгән җир участогын сатулар үткәрмичә бирү өчен, әлеге статьяның 2 пунктының 1-30 пунктчаларында каралган нигезләр булу.

5. Дәүләт яки муниципаль милектәге һәм төзелеше тәмамланмаган объект урнашкан җир участогын сатлар үткәрмичә арендага бирү әлеге объект төзелешен тәмамлау өчен бер тапкыр гамәлгә ашырыла:

1) төзелеше тәмамланмаган объект милекчесенә, дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын арендалау шартнамәсенең гамәлдә булуы туктатылу сәбәпле, элекке милекчедән алынган әлеге объектны сату буенча ачык сатулар нәтиҗәләре буенча сатып алынган милек хокукы;

